ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.08.2025 ел Баулы шәһәре №111

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 июлендәге 141 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга торглар үткәрмичә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 24 августындагы 171 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 113 номерлы, 2024 елның 25 ноябрендәге 174 номерлы, 2025 елның 27 февралендәге 22 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 15 июлендәге 141 номерлы карары белән расланган, муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга торглар үткәрмичә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (2023 елның 24 августындагы 171 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 113 номерлы, 2024 елның 25 ноябрендәге 174 номерлы, 2025 елның 27 февралендәге 22 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.8.2.1.пунктында:

3) пунктчада «йә» сүзләреннән соң «җир кишәрлеген федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә беренче чиратта яисә чираттан тыш сатып алуга хокукы булган бакчачылык яисә яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәттә катнашу (әгъзалык) хокукына ия булмаган граждан йә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга (әгәр мондый җир кишәрлеге бакчачы булса), шулай ук искәрмә нигезендә җир кишәрлеге сатып алуга хокуклы» сүзләрен өстәргә;»;

13 пунктчада) «хуҗалык» сүзеннән соң «торак пунктлар чикләрендә» сүзләрен өстәргә;

16) пунктчада «чикле» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров